**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 13** 30.11.**2020ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 15 июлендәге 209 номерлы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 15 июлендәге 209 номерлы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Бигеш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәнең 1.7 пунктына үзгәреш кертергә, аңа түбәндәге эчтәлекле абзацны өстәргә:

“-инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **И.Р.Вәлиев**